ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 29 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 694**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 июлендәге 371 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы медицина учреждениеләренең квалификацияле табиб кадрлары белән тәэмин итү» программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы нигезендә, Чистай муниципаль районының сәламәтлек саклау системасын квалификацияле табиблар кадрлары белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын кадрлар белән тәэмин итү турында» 2013 елның 18 июлендәге 503 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 июлендәге 371 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы медицина учреждениеләренең квалификацияле табиб кадрлары белән тәэмин итү» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар исемендә «2025» санын «2026» санына алмаштырырга;

1.2. программа исемен «2020-2026 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы медицина учреждениеләренең квалификацияле табиб кадрлары белән тәэмин итү» редакциясендә бәян итәргә

1.3. 1 нче «Программа исеме» бүлегенең 1 нче «Программа паспорты» графасында «2020-2026 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы сәламәтлек саклау системасының квалификацияле табиб кадрлары белән тәэмин итү» сүзләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

1.4. 1 нче «Программа паспорты» бүлекнең 3 нче «Программаны гамәлгә ашыру срогы» графасында «2025» санын «2026» санына алмаштырырга

1.5. 3 нче «Программаның максатлары һәм бурычлары» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

- «Программаның бурычлары түбәндәгеләр:
- халыкка дәвалау-профилактик медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны яхшырту,
- территориаль программа нигезендә кирәкле медицина ярдәме күләмен тәэмин итү,
- халыкка беренчел медицина-санитария һәм махсуслаштырылган ярдәм күрсәтүнең үтемлелеген һәм сыйфатын арттыру.»;

1.6. 4 нче «Программа чаралары составы» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «- программада катнашу өчен кандидатура сайлау»;

1.7. 5 нче «Программа гамәлгә ашыру механизмнары» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

- «Программада катнашу өчен кандидатура сайлау йомгаклары буенча грантларның акчаларын бирү белгечне эшкә урнаштыруга әзерләү һәм югары белем бирү программасы буенча белем алуга мәгариф турындагы шартнамәне төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

1.8. 6 нчы «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы сәламәтлек саклау системасының квалификацияле табиб кадрлары белән тәэмин итү» программасын ресурслар белән тәэмин итү» бүлеге исемендә «2025» санын «2026» санына алмаштырырга;

1.9. 6 нчы бүлекнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2020-2026 елларга программаның финанс чараларының гомуми күләме 8230294,00 сум тәшкил итә.»;

1.10. 6 нчы бүлекнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Грант акчаларын санау Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла»;

1.11. 7 нче «2020-2025 елларга Чистай муниципаль районы сәламәтлек саклау системасының квалификацияле табиб кадрлары белән тәэмин итү» муниципаль программасы чаралары планы» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. «2020-2026 елларга Чистай муниципаль районы медицина учреждениеләренең квалификацияле табиб кадрлары белән тәэмин итү» муниципаль максатчан программасы чаралары планы.

| № т/б | Чараның исеме | Еллар | Финанслау күләмнәре һәм чыганагы, сум. | Көтелә торган нәтиҗә | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджеты | | |
| 1 | Программада катнашу өчен кандидатлар сайлау | Ел саен (июнь-июль) | - | Программада катнашу өчен кандидатларның формалаштырылган исемлеге | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 2 | Грант бирү | 2020-2026<br><br>2020-2021 | 8230294,00<br><br>1340074,00<br>1275464,00<br>1071564,00 | Медицина кадрлары кытлыгы дәрәҗәсенең кимүе, Чистай муниципаль районы гражданна- | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма ко- |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021-2022<br>2022-2023<br>2023-2024<br>2024-2025<br>2025-2026 | 769564,00<br>607564,00<br>187686,00 | рына күрсәтелә торган медицина ярдәменең сыйфатын яхшырту | митеты |
| 3 | Программада катнашучыларны грант акчалары исәбеннән эшкә урнаштыру | 2021- 1 кеше<br>2022 – 4 кеше<br>2023 – 4 кеше<br>2024 – 2 кеше<br>2025 – 5 кеше<br>2026 – 2 кеше | - | Медицина кадрлары кытлыгы дәрәҗәсенең кимүе, Чистай муниципаль районы гражданнарына күрсәтелә торган медицина ярдәменең сыйфатын яхшырту | «Чистай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты |

»;

1.12. 8 нче «Программа гамәлгә ашыру сроклары» бүлегендә «2025» санын «2026» санына, «6» санын «7» санына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты карарының үз көчләрен югалтуын танырга:

- 29.08.2018 ел № 705;
- 17.08.2017 ел № 614;
- 26.10.2016 ел № 696;
- 16.10.2015 ел № 611;
- 23.10.2014 ел № 675;

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән үзгәрешләр 2020 елдан башлап үз эшчәнлеген җәелдерә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов